РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**КАРАР**
**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«23» май 2017ел № 1

«Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында, аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле, муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы һәм "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында" 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 4 пункты нигезендә карар бирәм:

1. Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 7 апрелендәге 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://buinsk.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы,
ТР Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.С. Валиева

Карарга 1 нче кушымта

Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл
җирлегенең җирле үзидарә органнарында, аларны биләү
коррупция куркынычлары белән бәйле, муниципаль
хезмәт вазыйфалары исемлеге

1 бүлек. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
- башкарма комитет секретаре